## Тормыш җыры

Без яшибез бу дөньяда
Шатлык һәм бәхет өчен
Тормыш юлын үткән чакта
Киртәләр үтәр өчен.

Без килгәнбез вакытлыча
Гомер юлын үтәргә
Туганнар һәм дуслар белән
Кайгыларны бүләргә

Дөнья назы, сөю хисе
Үтеп керә җаннарга
Җан җылысы, рәхмәт сүзе
Балкый безнең йөзләрдә.

## Очрашу

Гомерләрнең бик тиз үтә мизгелләре
Сихри уйлар йөри күңелдә
Яхшы кешеләр белән очрашканда
Рухи байлыгыбыз көч ала.

Туган якның үскән нигезләре
Һәрчак безне тарта ерактан
Беренче кат аваз сузган җирләр
Туган җирең — безне кан тарта.

Канатлары җәеп очкан кашлар сыман
Таралыша үскәч балалар
Сөйләшерләр еллар үткәч сөенеп
Таныш йөзләр, таныш тавышлар.

## Яшьлегебез

Кая алып бара безнең үткән еллар?
Ни сөйләрбез ахры чикләрдә?
Үтсәк иде тормыш баскычларын
Йомгаклатып тик бер күпердә
Яшьлегебез калды күңелдә...
Кадерләрен белик, дуслар!
Үткән көнне, үткән тормышны
Бер очрашып сөйләшәсе килер
Сагынып балачакны, дусларны
Яшьлегебез калды йөрәктә...
Кайчак бездә яңа фикер туа
Кайтасы дип узган мизгелгә
Карлыгачлар кебек безнең уйларыбыз
Очып китә бик тә еракка
Яшьлегебез калды еракта...

**Нурия ВАХИТОВА.**
**Богырыслан.**





ТАТАР ХАЛЫК АШЛАРЫ

## Карабодай бәлеше

Карабодай ярмасы белән пешергән бәлеш, бигрәк тә авылларда, тансык сыйлардан санала. Бу бәлешне итсез генә, тик бик күп итеп май (эреткән атланмай, сары май яисә каз мае) салып пешерәләр. Аны гөбәдия кебек биек итеп әзерлиләр.

Карабодай ярмасын башта табада кыздыралар да тозлы сөтте бераз бөрттереп алалар, суынгач, бәлеш ясыйлар. Май һәм тоз сибеп, суган өстәп, болгаталар.

Карабодай бәлешенә дә камырны башка бәлешләргә баскан кебек басалар, тик азрак шикер комы гына өстиләр.

Табынга шулпалы ит бәлеше кебек чыгаралар.

**Бер бәлешкә: 1 — 1,5 кг камыр, 1 кг карабодай ярмасы, 200 — 300 г сары май, 300 г суган, тоз, борыч.**

## Чебеш бәлеше

Әче камыр әзерлиләр. Бәлешне түгәрәк итеп (табада) яисә озынча итеп (калайда) ясыйлар.

Чистарткан, юган чебәшнең итен сөягеннән аералар да вак кына турыйлар. Канатларын һәм башка ваграк сөякләрен шул килеш салалар. Итне савытка салып, тоз, борыч сибеп, әйбәтләп болгаталар.

Камырны куна тактага җәеп, майлы табага салалар, камыр өстенә каты итеп пешереп вак кына тураган йомырка сибәләр; аннары, чебеш итен салып, өстенә тагын йомырка, башлы суган салалар да күп итеп май сибәләр. Бәлешнең өстен тагын камыр җәеп каплыйлар, 10 минут кабарткач, мичкә куялар. Бәлешнең йөзе килгәч, аны мичтән алып, өстенә юеш кәгазь каплыйлар. Чебеш бәлеше 45-60 минут чамасы пешә.

Бәлешне мичкә куюга, чебешнең сөякләреннән шулпа пешерәләр. Бәлешне мичтән алып капкачын аз гына кисеп шулпа салалар да тагын мичкә куялар. Бәлешне табынга табасы белән чыгаралар.

**Бер бәлешкә: 1 — 1,2 кг камыр, 500 — 600 г лы чебеш, 8 — 10 йомырка, 150 — 200 г май, 100 — 150 г суган, тоз, борыч.**

## Чуенда пешкән бәлеш

Бәлешне чуенда кыш көне, гадәттә мич якканда әзерлиләр. Эре итеп бәрәңгә туралар да тирән кастрюльгә салалар, шунда чи яисә майсыз гына кыздырып алган суган, кузы чикләвеге кадәр итеп тураган ит, борыч, лавр яфрагы өстиләр. Барысын бергә әйбәтләп болгаталар. Чуен төбенә - май, аның өстенә - юка итеп җәйгән камыр, тагын май һәм әзер эчне салалар, барысы күмелерлек кенә шулпа өстиләр. Чуенның өстен каплап мичкә куялар. Бәлеш 3 — 4 сәгатьтән пешеп җитә. Шулай да аны ашыгып алмаска кирәк: бәлеш шулпасы белән бераз томаланып торса, тәмлерәк була. Бәлешнең эчен болгатмыйча гына, катлам-катлам итеп: ит, суган, бәрәңге, май һәм шулпа, алар арасына тоз, борыч сибеп салырга да мөмкин. Бәрәңге урынына — карабодай, дөге, борай, бодай ярмасы, ә сыер яки сарык ите урынына кош ите дә алырга ярый.

**2 кг бәрәңге, 1,5 кг ит, 200 г суган, 200 г май, кирәгенчә тоз, борыч.**

# НАМАЗ ВАКЫТЛАРЫ



(время местное)

| июнь | Фаджр Иртә | Восход Кояш чыга | Зухр Өйлә | Аср Икенде | Магриб Ахшам | Иша Ясту |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 5-07 | 6-07 | 15-10 | 20-54 | 22-54 | 24-24 |
| 2 | 5-06 | 6-06 | 15-10 | 20-55 | 22-55 | 24-25 |
| 3 | 5-05 | 6-05 | 15-10 | 20-56 | 22-56 | 24-26 |
| 4 | 5-05 | 6-05 | 15-10 | 20-57 | 22-57 | 24-27 |
| 5 | 5-04 | 6-04 | 15-10 | 20-58 | 22-58 | 24-28 |
| 6 | 5-04 | 6-04 | 15-10 | 20-59 | 22-59 | 24-29 |
| 7 | 5-03 | 6-03 | 15-10 | 21-00 | 23-00 | 24-30 |
| 8 | 5-02 | 6-02 | 15-10 | 21-01 | 23-01 | 24-31 |
| 9 | 5-01 | 6-01 | 15-10 | 21-02 | 23-02 | 24-32 |
| 10 | 5-01 | 6-01 | 15-10 | 21-03 | 23-03 | 24-33 |
| 11 | 5-01 | 6-01 | 15-10 | 21-04 | 23-04 | 24-34 |
| 12 | 5-00 | 6-00 | 15-10 | 21-05 | 23-05 | 24-35 |
| 13 | 5-00 | 6-00 | 15-10 | 21-05 | 23-05 | 24-35 |
| 14 | 5-00 | 6-00 | 15-10 | 21-06 | 23-06 | 24-36 |
| 15 | 4-59 | 5-59 | 15-10 | 21-06 | 23-06 | 24-36 |
| 16 | 4-59 | 5-59 | 15-10 | 21-06 | 23-06 | 24-36 |
| 17 | 4-59 | 5-59 | 15-10 | 21-07 | 23-07 | 24-37 |
| 18 | 4-59 | 5-59 | 15-10 | 21-07 | 23-07 | 24-37 |
| 19 | 4-59 | 5-59 | 15-10 | 21-07 | 23-07 | 24-37 |
| 20 | 4-59 | 5-59 | 15-10 | 21-08 | 23-08 | 24-38 |
| 21 | 4-59 | 5-59 | 15-10 | 21-08 | 23-08 | 24-38 |
| 22 | 4-59 | 5-59 | 15-10 | 21-08 | 23-08 | 24-38 |
| 23 | 5-00 | 6-00 | 15-10 | 21-08 | 23-08 | 24-38 |
| 24 | 5-00 | 6-00 | 15-10 | 21-08 | 23-08 | 24-38 |
| 25 | 5-00 | 6-00 | 15-10 | 21-09 | 23-09 | 24-39 |
| 26 | 5-01 | 6-01 | 15-10 | 21-09 | 23-09 | 24-39 |
| 27 | 5-02 | 6-02 | 15-10 | 21-09 | 23-09 | 24-39 |
| 28 | 5-03 | 6-03 | 15-10 | 21-09 | 23-09 | 24-39 |
| 29 | 5-03 | 6-03 | 15-10 | 21-09 | 23-09 | 24-39 |
| 30 | 5-03 | 6-03 | 15-10 | 21-09 | 23-09 | 24-39 |

**Данные предоставлены Бугурусланским муфтиятом. Возможна разница во времени в сравнении с другими источниками, на 3-5 минут.** (Время летнее).

ТУГАН ЯК
РОДНОЙ КРАЙ

**E-MAIL:** tugan-iak-asekeevo@yandex.ru

**УЧРЕДИТЕЛЬ:**
ТАТАРСКАЯ НАЦИОНАЛЬНО КУЛЬТУРНАЯ АВТОНОМИЯ
**АДРЕС РЕДАКЦИИ:**
С.АСЕКЕЕВО, УЛ.ЧАПАЕВА 24.
**ТЕЛЕФОН:** (353-51) 2-22-81

Распространяется в Асекеевском, Абдулинском, Бугурусланском, Матвеевском, Пономаревском, Северном районах. Свидетельство о регистрации ПИ №ТУ 56-00065, выданное Управлением Федеральной службы по надзору в сфере связи и массовых коммуникаций по Оренбургской области.

Газета отпечатана в Бугурусланской типографии. 461600, г. Бугуруслан, ул. Революционная, 14.

Цена свободная. ТИРАЖ: 2000 ЭКЗ.

**Главный редактор: Фарит НУГУМАНОВ**